| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КИЛЬДЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КИЛДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | |
|---|---|
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
| 27.06.2024 | 62 |

с. Кильдеево

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты баш бухгалтерының хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» 23.04.2019 №11 карары белән расланган Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты баш бухгалтерының хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (Башкарма комитетның 17.11.2020 ел №18, 14.10.2022 ел №20, 27.01.2023 ел №4 карарлары редакциясендә)

Үзәкләштерелгән бухгалтерлар, баш бухгалтерлар һәм бухгалтерлар җитәкчеләренең һәм белгечләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. "Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты баш бухгалтерының хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында" нигезләмәнең 3 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- "Бухгалтерларның вазифа окладлары" таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Вазыйфа | Халык саны булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | 3,5 меңгә кадәр кеше | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш бухгалтер | 23700 сум | 25000 сум |

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
К
и
л
д
и

а
в
ы